# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы
Зирекле авыл җирлеге составына керүче
Зирекле авылы торак пунктында

2020 елның 13 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Зирекле авыл җирлеге составына керүче Зирекле авылы торак пунктында гражданнар җыены нигезендә

**КАРАР ИТТЕ:**

1. 2021 елда Зирекле авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку студентларыннан, Россия Армиясе сафларына ашыгыч хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш, гражданнарның үзара салымын 500 сум күләмендә кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге максатларга җибәрергә:
 - авыл эчендәге юлларны төзекләндерү һәм карап тоту (вак таш сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча хезмәт өчен түләү, кардан чистарту, урамнарны чабу);

 - авыл җирлегенең торак пунктында урамнарны яктырту (урам фонарьлары, исәпкә алу приборлары сатып алу, СИП үткәрү, килешү буенча хезмәт өчен түләү);
3. Әлеге карарны Зирекле авыл җирлегенең рәсми сайтында, хокукый мәгълүмат порталында, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Зирекле авыл җирлеге Советы бинасында мәгълүмат стендында урнаштырырга.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Зирекле авыл җирлеге башлыгы В.А.Данилова